**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422615 с. Чирпы,
ул. Заводская, д.22
тел: 8 (84378) 2-91-45
E-mail: Chirp.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422615 Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 йорт,
тел: 8 (84378) 2-91-45
E-mail: Chirp.La@tatar.ru

2023 елның 7 ноябре 13 номер

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегенең Чирпы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

2023 елның 15 ноябрендә Чирпы мәдәният йорты бинасында ТР, Лаеш муниципаль районы, Чирпы авыл җирлеге, Чирпы авылы, Заводская 20а адресы буенча Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегендә Чирпы торак пунктында,үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Чирпы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Чирпы торак пунктында Приовражная урамындагы вак ташлар җәю.

- Чирпы торак пунктын төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–

адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Чирпы**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы: Зотин Р.Ю.**